**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Кече Карагуҗа торак пунктында**

**«13» нче ноябрь 2019 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Кече Карагуҗа торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Кече Карагуҗа торак пунктында 2020 елда, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, 1 һәм 2 группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән кала, Кече Карагуҗа торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшүсмердән 300,00 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юлны төзекләндерү өчен инерт материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яшел Үзән муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Олы Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Олы Карагуҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (мәдәният йорты бинасы), Олы Күлбаш авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче** **М.Р. Минһаҗев**

**Олы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы, Совет Рәисе** **М.Р. Минһаҗев**